| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА СОСНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>СОСНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 октябрь 2025 нче ел №21

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач район Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында»2025 елның 11 сентябрендәге 343 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сосна авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сосна авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында" 28.05.2020 №129 Карары белән (29.06.2022 елнын №42, 26.10.2023 елнын №82 үзгәрешләре белән), гражданнарның Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен гавами тыңлаулар уздыру юлы белән үзгәртү турындагы мәсьәләне тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында

Карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрүне «2025 елның 25 октябренә» 11.00 сәгатькә Сосна авыл җирлегенең Сосна авылы мәдәният йорты бинасында түбәндәге адреста билгеләргә: ТР, Балтач районы, Түбән Сосна авылы, Герой Сәрвәр ур., 2 йорт.
2. Гавами тыңлауларда карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2025 елның «24» октябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Түбән Сосна авылы, Герой Сарвар урамы, 2 йорт, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сосна авыл җирлеге башкарма комитеты, консультация өчен телефон : 8(843)68-3-27-33.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (https://baltasi.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлегенең: ТР, Балтач районы, Түбән

Сосна авылы, Герой Сәрвәр ур., 2 йорт буенча урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.


4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Сосна авыл җирлеге башлыгы Ф.С.Габдрахманов

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Сосна авыл җирлеге
башлыгының 06.10.2025
елдагы № 21 карарына
кушымта

**Карта-схема**

границ муниципальных образований
с учетом изменений




## Условные обозначения

- -границы поселений
- -административный центр поселения
- -населенный пункт
- -территория Сосновского сельского поселения, включаемая в состав муниципального образования «поселок городского типа Балтаси»
- -территория Норминского сельского поселения, включаемая в состав